**Республика Татарстан**
**Лаишевский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Орловского**
**сельского поселения**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Орлов**
**авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

422629 ул.Олимпийская д.2 а, д. Орел,
Orel.La@tatar.ru, тел/факс 8(84378)4-49-10

р/с 40204810100000440016 ИНН 1624009334

**2025 елның 01 августы** **12 номер**

# КАРАР

## 16:24:140101:1159 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 40 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 19.12.2018нче елның 19 декабрендәге 94 нче номерлы Орел авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау максатларында Орел авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 27 августына 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге, Орел авылы, Радужная урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Орел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән индивидуаль торак йортлар төзү зонасында 16:24:140101:1159 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга Миганова Ольга Николаевнага рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә,:

- җир кишәрлеге чикләреннән көньяктан (2 нче ноктадан 3 нче ноктага кадәр) – 2,5 м га кадәр; төньяктан (6 нчы ноктадан 1 нче ноктага кадәр) 2,5 м га кадәр минималь чигенешләрне киметү өлешендә.

2. Карар проекты буенча гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын Орел авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында уздырырга, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Лаеш районы, Орел авылы, Олимпия ур., 2А йорт..

3. Карар проекты белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2025 елның1 августыннан 2025 елның26 августына кадәр 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин.

4. 3 пунктта күрсәтелгән чор дәвамында гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне түбәндәге тәртиптә кертергә хокуклы:

- язма рәвештә түбәндәге адрес буенча гавами тыңлауларны оештыручы адресына: Татарстан Республикасы, Лаеш районы Орел авылы, Олимпия урамы, 2в йорт

- проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Орел авылы, Олимпия ур., 2а йорт

- шулай ук гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә яисә телдән бирелергә мөмкин.

Гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлауларны оештыручыларга ризалыгын бирәләр.

5. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орел авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Җитекче** **В.И.Фетилина**